**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 декабрендәге 4773 номерлы карары**

**«2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында**

Хокук бозуларны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру, җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында»гы федераль закон (2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 5 ноябрендәге 906 номерлы карары редакциясендә) нигезләмәләрен исәпкә алып, һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 10 августындагы 2246 номерлы карары редакциясендә) нигезендә **карар бирәм:**

1. «2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасын (алга таба – муниципаль программа) әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә расларга:

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак (функциональ) һәм территориаль органнары, Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы башка оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.1. муниципаль программаның 1 номерлы кушымтасы нигезендә муниципаль программаны гамәлгә ашыру чараларын үтәргә;

2.2. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына муниципаль программаның үтәлеше турында квартал саен, ведомство программалары чикләрендә гамәлгә ашырыла торган чараларны һәм финанслау күләмнәрен исәпкә алып, муниципаль программаның 3 номерлы кушымтасы нигезендәге формада хисап тапшырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына:

3.1. квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 нче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә әлеге карарның 2 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга;

3.2. ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшырырга;

3.3. Муниципаль программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4267 номерлы «2016-2020 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау программасы турында»гы карарын (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге 4571 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 1873 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 2995 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы 947 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 1596 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы 159 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3988 номерлы, 2020 елның 26 ноябрендәге 3466 номерлы, 2021 елның 30 июнендәге 1585 номерлы, 2023 елның 1 августындагы 2177 номерлы, 2024 елның 16 апрелендәге 1570 номерлы, 2024 елның 11 декабрендәге 5126 номерлы, 2025 елның 16 апрелендәге 1202 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип санарга.

5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөклим.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
30 декабрендәге 4773 номерлы
карарына 1 номерлы кушымта

**«2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасы**
**Муниципаль программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа атамасы | «2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – муниципаль программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты |
| Муниципаль программа координаторы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты |
| Программаның төп башкаручылары | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе, Казан шәһәре |

| | |
|---|---|
| | Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча), «Казан шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча), «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Транспорттагы Казан линия идарәсе (килешү буенча), «Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять-башкарма инспекциясе» федераль казна учреждениесе (килешү буенча), Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәге (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле тору урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге (килешү буенча), «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» коомерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы (килешү буенча), Татарстан |

| | |
|---|---|
| | Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы (килешү буенча) |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Муниципаль программаның максатлары:<br>Казан шәһәре территориясендә җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлектә исәптә торучы балигъ булмаганнар санын киметү максатыннан, киберҗинаятьчелекне дә кертеп, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауның нәтиҗәлелеген арттыру.<br>Муниципаль программаның бурычлары:<br>- хокук бозулар һәм җинаятьләрне кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү;<br>- мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендәге хокук бозуларны профилактикалау;<br>- халыкның иминлегенә янарга мөмкин булган куркынычларны профилактикалау;<br>- шәһәр урамнарында хокук тәртибен тәэмин итү, урам җинаятьчелеген профилактикалау, урамда кылына торган җинаятьләрне профилактикалау, җәмәгать урыннарында һәм торак секторда хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен заманча техник чараларны гамәлгә кертү;<br>- гражданнар күпләп йөри торган урыннарда һәм эре иҗтимагый, сәяси, мәдәни чаралар уздырганда җинаять кылуларны һәм хокук бозуларны кисәтү;<br>- эшнең инновацион формаларын һәм ысулларын кулланып, балалар һәм |

<table>
<tr><td></td><td>яшьләрнең деструктив тәртибен профилактикалау һәм тәрбияләү;<br>- балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләрдә исәптә торучы балигъ булмаганнар арасында профилактика эше, аларны эшкә һәм ял итү чараларына җәлеп итү;<br>- җәзасын үтәгән затлар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм аларны яңадан җәмгыятькә яраклаштыру;<br>- халыкның алкоголь һәм наркотиклар куллану дәрәҗәсен киметү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чаралары;</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары</td><td>2026-2028 еллар.<br>Программа бер этапта тормышка ашырыла</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау күләме</td><td>Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен 1 329 267,4 мең сум каралган, шулардан: 1 283 309,8 мең сум – Казан шәһәре бюджетыннан һәм 45 957,6 мең сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.<br><br><table>
<tr><th>Ел</th><th>Гомуми сумма (мең сумнарда)</th><th>Казан шәһәре бюджеты (мең сумнарда)</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты (мең сумнарда)</th></tr>
<tr><td>2026</td><td>402 980,6</td><td>387 742,1</td><td>15 238,5</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>441 803,1</td><td>426 478,7</td><td>15 324,4</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>484 483,7</td><td>469 089,0</td><td>15 394,7</td></tr>
</table><br>Искәрмә. Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә. Аңа, Казан шәһәре бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Әлеге программа белән алдан каралмаган чыганаклардан өстәмә чаралар җәлеп ителгән</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | очракта, программаның заказ бирүчесе аңа тиешле үзгәрешләр кертә.<br>Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән, еллар буенча бүленгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Муниципаль программаның чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2025 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, 100 мең кешегә туры килгән җинаятьләр санының кимүе;<br>- мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләрнең ачылу өлеше әлеге төрдәге теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санында 2,0 процентка арту;<br>- теркәлгән җинаятьләрнең гомуми күләмендә ачылган җинаятьләр өлеше 3,9 процентка арту;<br>- урамнарда кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 2,1 процентка кимү;<br>- җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 1,9 процентка кимү;<br>- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 1,0 процентка кимү;<br>- элек җинаять кылган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 4,0 процентка кимү;<br>- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 3,0 процентка кимү |

## I. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы

2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы федераль

законны (аңа 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезләмәләрен (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 5 ноябрендәге 906 номерлы карары редакциясендә) исәпкә алып, һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 10 августындагы 2246 номерлы карары редакциясендә) нигезендә «2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасы эшләнде.

Әлеге муниципаль программа җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү, мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен куллану белән бәйле хокукка каршы гамәлләрне профилактикалау максатында, алкоголизмга, наркоманиягә, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә һәм сукбайлыгына, шулай ук законсыз миграциягә каршы көрәшне активлаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Муниципаль программаның чаралары тугыз бүлеккә берләштерелгән: хокук бозулар һәм җинаятьләрне кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү; мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау; халыкның иминлегенә янарга мөмкин булган куркынычларны профилактикалау; шәһәр урамнарында хокук тәртибен тәэмин итү, урам җинаятьчелеген профилактикалау, урамда кылына торган җинаятьләрне профилактикалау, җәмәгать урыннарында һәм торак секторда хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен заманча техник чараларны гамәлгә кертү; гражданнар күпләп йөри торган урыннарда һәм эре иҗтимагый, сәяси, мәдәни чаралар уздырганда җинаять кылуларны һәм хокук бозуларны кисәтү; эшнең инновацион формаларын һәм ысулларын кулланып, балалар һәм яшьләрнең деструктив тәртибен профилактикалау һәм тәрбияләү; балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләрдә исәптә торучы балигъ булмаганнар арасында профилактика эше, аларны эшкә һәм ял итү чараларына җәлеп итү; җәзасын үтәгән затлар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм аларны

яңадан җәмгыятькә яраклаштыру; халыкның алкоголь һәм наркотиклар куллану дәрәҗәсен киметү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чаралары.

Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты хокук бозуларны профилактикалау субъектлары эшчәнлеген координацияли һәм муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруны контрольдә тота.

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4267 номерлы карары белән кабул ителгән «2016-2025 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау программасы»н гамәлгә ашыру тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары базасында полиция хезмәткәрләре һәм җәмәгатьчелек арасында тыгыз элемтә һәм хезмәттәшлек урнаштыруга, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм халык дружиналары эшчәнлеген координацияләргә мөмкинлек бирде.

Хокук бозуларны, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә, анализлау муниципаль программаны бергә башкаручы – Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (аның җитәкчелеге Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча ведомствоара комиссия составына кертелгән) тарафыннан, шулай ук хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча ведомствоара комиссиянең секретариаты тарафыннан даими рәвештә йомгаклау утырышларында башкарыла.

Шулай ук хокук бозуларны анализлау Казан шәһәре Думасының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенең, шул исәптән 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы «Полиция турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Транспортта Казан линия идарәсенең җирле үзидарә органнары алдында еллык хисаплары кысаларында карап тикшерү предметы булып тора. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе белән берлектә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау белән бәйле оештыру-методик чаралар үткәрү планлаштырыла.

Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау кысаларында муниципаль программа гомуми белем бирү һәм югары уку йортларында укучыларга юнәлдерелгән цифрлы куркынычсызлык өлкәсендә профилактик чаралар комплексын оештыру һәм гамәлгә ашыру белән тулыландырылачак, анда түбәндәге төп аспектлар исәпкә алыначак:

- мәгълүмат материалларын (билбордлар, баннерлар, листовкалар, видео һәм фото материаллар) киң куллануны оештыру;

- шәһәрнең гомуми белем бирү һәм югары уку йортларында укучылар арасында хокук бозуларны, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре кулланып кылынганнарны профилактикалау буенча чаралар комплексы, яшьләр өчен шәһәркүләм квизлар һәм квестлар, проектлар конкурсы, киберкуркынычсызлык буенча «Киберклик» форумы, листовкалар, мультфильмнар, комикслар, подкастлар һәм вебинарлар эшләү, «Яшәү яме» проектының «Кешеләр һәм еллар» лекторийлары кысаларында цифрлы мохиттә алдап урлашуны профилактикалау буенча видеороликлар күрсәтү, шулай ук муниципаль интернет-ресурсларда, шәһәрнең реклама конструкцияләрендә кисәтү баннерлары урнаштыру.

ИТ-технологияләр кулланып алдап урлашуны профилактикалауның кискен социаль ихтыяҗын исәпкә алып, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе һәм «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте арасында торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре өчен счет-фактураларда профилактик материалларны бушлай урнаштыру өчен хезмәттәшлек оештырылачак.

2025 елның 9 аенда 16 071 җинаять теркәлгән. Бу сан узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 17,8%ка кимрәк, шул ук вакытта аеруча авыр һәм авыр җинаятьләр саны 5 932 берәмлектән 5 999 берәмлеккә, яки 1,1 % арткан.

Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре ярдәмендә кылынган җинаятьләр саны 25,2%ка кимегән (12 209 берәмлектән 9 133 берәмлеккә кадәр), шул исәптән дистанцион алдап урлашу 10,4%ка (4 441 берәмлектән 3 979 берәмлеккә кадәр). Әлеге категориядә теркәлгән урлашулар саны 25,5% ка, 1267 берәмлектән 944 берәмлеккә кимегән. Шул ук вакытта мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре ярдәмендә кылынган җинаятьләрнең тикшерелгәннәре саны 1 949 берәмлектән 1 786 берәмлеккә, ягъни 8,4% ка кимегән.

Дистанцион ысул белән кылынган җинаятьләрне профилактикалау максатыннан, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тарафыннан даими рәвештә ведомство сайтының яңалыклар тасмасында Казан полициясе хезмәткәрләренең әлеге төр җинаятьләрне ачу һәм профилактикалау эшчәнлеген яктыртуга юнәлтелгән материаллар урнаштырыла. Шулай итеп, 2025 елның 9 аенда ведомствоның рәсми сайты яңалыклар тасмасында 182 мәгълүмат хәбәре тәкъдим ителгән, алар нигезендә массакүләм мәгълүмат чараларында 1170 материал урнаштырылган.

Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау өчен видеокүзәтүнең техник чаралары актив кулланыла. Шәһәр буенча 52 меңнән артык видеокүзәтү камерасы урнаштырылган (52 810 берәмлек), шул исәптән 1391 берәмлек – «Имин шәһәр» программасы, 20 048 берәмлек – «Имин ишегалды» программасы кысаларында. Хәзерге вакытта Казан шәһәренең күпфатирлы йортларында 20 048 видеокамера, 7 120 камера – IP-домофоннарда, җәмәгать урыннарында һәм шәһәр урамнарында 5 058 камера урнаштырылган. Видеомониторинг белән шәһәрнең 47 паркы һәм скверы колачланган. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларының видеокүзәтү системалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 26 октябрендәге 2399-р номерлы (2022 елның 31 октябрендәге 2337-р номерлы үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган, кешеләр күпләп җыела торган урыннарны җиһазландыру буенча тәкъдимнәргә туры килә.

Видеокүзәтү системаларын кулланып 678 җинаять ачылган, 703 административ хокук бозу ачыкланган.

2025 елның 9 ае эчендә Казан шәһәренең җәмәгать урыннарында кылынган 3 424 җинаять теркәлгән, җинаятьләрнең гомуми массивында әлеге категориядәге җинаятьләрнең чагыштырма күләме 21,3% тәшкил иткән, бу 2024 елның 9 ае белән чагыштырганда 4% ка күбрәк (17,3%).

Шулай ук 912 урам җинаяте теркәлгән, бу теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санының 5,7%ын тәшкил итә, узган елның шул ук чоры өчен бу күрсәткеч 6,3% тәшкил иткән.

Полициянең аерым игътибар үзәгендә – балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган хокук бозуларны профилактикалау һәм катлаулы тормыш хәлендә калган балаларга, имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм девиант тәртипле балалар белән эшләү юлы аша ярдәм күрсәтү.

2025 елның 9 аенда яшүсмерләр тарафыннан кылынган җинаятьләр саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 28,8%ка, 326 берәмлектән 232 берәмлеккә кадәр кимегән. Яшүсмерләр җинаятьчелеге дәрәҗәсе арткан һәм 4% тәшкил иткән. Яшүсмерләр җинаятьчелегенең югары дәрәҗәдә булуының бер сәбәбе – күп кенә балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль челтәрләрдә һәм интернет-мессенджерлар ярдәмендә аралашу төп ял итү формасына әйләнүе, шул ук вакытта психологик яшь үзенчәлекләре аркасында алар интернет киңлекләреннән чыгып эшләнә торган төрле куркынычларга, шул исәптән җинаятьчел бергәлекләр, экстремистик һәм террористик төркемнәр һәм берләшмәләр эшчәнлегенә кереп китүгә, үз-үзенә кул салуга, криминаль

нормалар, кыйммәтләр һәм үз-үзеңне тоту модельләрен пропагандалауга аеруча тиз бирешүчән.

2025 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча 177 яшүсмер җинаять җаваплылыгына тартылган, җинаятьләрдә катнашучыларның 111 е (яки 62,7%) – шәһәрнең гомуми белем бирү учреждениеләре (мәктәпләр, гимназияләр, лицейлар) укучылары.

Казан шәһәре бүлекчәләрендә җәмгыятькә каршы гамәлләр кылучы 33 төркем исәптә тора, аларның составына 82 балигъ булмаган бала керә. Әлеге категориядәге яшүсмерләр белән адреслы профилактик эш алып барыла. Бүгенге көндә шәһәрдә балигъ булмаганнарның төркемле җинаятьчелегенең массакүләм чагылышлары теркәлмәгән.

Рецидив җинаятьчелекне профилактикалауга зур игътибар бирелә. 2025 елның узган чорында элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 5,1% ка, 2 006 берәмлектән 1 904 берәмлеккә кадәр кимегән. Гомуми җинаятьләр санында рецидив җинаятьчелек өлеше узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 0,6% ка кимегән (33,5% тан 32,9% ка кадәр).

Әлеге категориягә караган гражданнарның эшкә урнашмаган булуы – алар тарафыннан кылынган күпсанлы җинаятьләрнең төп сәбәпләреннән берсе. Әйтик, элек хөкем ителгәннәрнең 81,3% ы (1 226 кешенең 997се) рәсми рәвештә эшкә урнаштырылмаган, ягъни аларның даими кереме юк.

2025 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 16,9% ка, 1000 берәмлектән 831 берәмлеккә кадәр кимегән. Бу төр җинаятьләрнең саны гомуми җинаятьләр санының 14,4% ын тәшкил иткән.

Алкоголь продукциясе әйләнеше өлкәсендәге законнарны үтәү максатыннан полиция хезмәткәрләре тарафыннан 2025 елның 9 ае йомгаклары буенча төрле объектларда якынча 23 мең (23 374 берәмлек), шул исәптән 634 сәүдә объектында, тикшерү уздырылган, алар нәтиҗәсендә 92 административ протокол төзелгән. 439,3 литр алкоголь һәм спиртлы продукция алынган. Профилактик чаралар барышында спиртлы эчемлекләр кулланган һәм җәмәгать урыннарында исерек хәлдә күренгән өчен 1 068 кеше административ җаваплылыкка тартылган.

Җәмәгать тәртибен саклау эшендә Татарстан Республикасы хөкүмәт органнары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты актив ярдәм күрсәтә, шуның нәтиҗәсендә шәһәр территориясендә участок буенча полициянең участок вәкилләре өчен алты административ-торак комплекс (өчесе – Совет районында, икесе – Идел буе районында һәм берсе – Авиатөзелеш районында) һәм

88 җәмәгать тәртибен саклау пункты эшли. 2025 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча җәмәгать тәртибен саклау пункты хезмәткәрләре тарафыннан 9 меңнән артык (9 652) административ хокук бозу ачыкланган, 7 млн сумнан артык штраф салынган. Бүгенге көндә 36 җәмәгать тәртибен саклау пунктына (биналарны косметик ремонтлау, җылыту системасын, санузелларны ремонтлау, тәрәзәләрне, ишекләрне, сантехниканы, түбәләрне алмаштыру һ.б.) ремонт таләп ителә.

Җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә гражданнарны җәлеп итү эшен оештыру зур әһәмияткә ия.

Казан шәһәре территориясендә гомуми саны 1638 кешедән торган 267 халык дружинасы эшли. Мәгариф уку йортлары (югары уку йортлары, урта һөнәри уку йортлары) базасында барлыгы 477 кешедән торган 31 дружина, оешмалар һәм предприятиеләр базасында 633 кешедән торган 51 дружина төзелде. Гражданнарның инициатив төркемнәре исәбеннән 563 кешедән торган 185 «ишегалды дружинасы» төзелде.

Дружиначылар җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү өчен зур шәһәр чараларын үткәргәндә җәлеп ителәләр. Халык дружиналары полициянең участок вәкилләре белән берлектә административ участокларда патрульлек итәләр, Казан метрополитены станцияләрендә патруль-пост хезмәте хезмәткәрләренә, шулай ук массакүләм чаралар үткәрү вакытында Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе патруль-пост хезмәтенең аерым батальоны һәм дәүләт автомобиль инспекциясе бүлеге хезмәткәрләренә ярдәм итәләр.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең дәүләт автомобиль инспекциясе бүлеге белән берлектә «Курс» студентлар дружинасы һәм «Казанда шәһәрендә юл хәрәкәте иминлегенә ярдәм итү» халык дружинасы эшчәнлеге гамәлгә ашырыла.

2025 елның 9 аенда халык дружиначылары 6 массакүләм чара үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауда катнашты.

Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә торак секторда хокук бозуларны профилактикалау буенча белгечләр (полиция участок вәкилләре ярдәмчеләре), балигъ булмаганнар арасында гаиләдәге уңышсызлыкларны һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспекторлар (балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе ярдәмчеләре) һәм полициянең патруль-пост хезмәте белән бергә эшләүче муниципаль хезмәткәрләр (патруль-пост хезмәте ярдәмчеләре) зур эш башкаралар. Торак секторда хокук бозуларны профилактикалау буенча белгечләр 2025 елның 9 аенда полициянең участок

вәкилләре белән берлектә 183 рейд үткәрде һәм гражданнарның 124 мөрәҗәгатен һәм хәбәрен тикшерде.

Балигъ булмаганнар арасында гаиләдәге уңышсызлыкларны һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспекторлар Казан шәһәре полициясенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләре хезмәткәрләренә 3 җинаятьне һәм 677 административ хокук бозуны ачуда ярдәм күрсәттеләр, шул исәптән балигъ булмаганнарга карата 116, үз бурычларын үтәмәүче ата-аналарга карата 306 административ беркетмә төзелде. Моннан тыш, муниципаль хезмәткәрләр шәхсән ТР Административ хокук бозулар кодексының 3.11 статьясы буенча 41 административ беркетмә төзеде.

## II. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, муниципаль программаның төп максатлары һәм бурычлары

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның төп максаты булып Казан шәһәре территориясендә җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан хокук бозуларны һәм җинаятьләрне, шул исәптән киберҗинаятьчелекне профилактикалауның нәтиҗәлелеген арттыру тора.

Максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү таләп ителә:

1. хокук бозулар һәм җинаятьләрне кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

2. мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау;

3. халыкның иминлегенә янарга мөмкин булган куркынычларны профилактикалау;

4. шәһәр урамнарында хокук тәртибен тәэмин итү, урамда кылына торган җинаятьләрне профилактикалау, җәмәгать урыннарында һәм торак секторда хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен заманча техник чараларны гамәлгә кертү;

5. гражданнар күпләп йөри торган урыннарда һәм эре иҗтимагый, сәяси һәм мәдәни чаралар уздырганда җинаять кылуларны һәм хокук бозуларны кисәтү;

6. эшнең инновацион формаларын һәм ысулларын кулланып, балалар һәм яшьләрнең деструктив тәртибен профилактикалау һәм тәрбияләү;

7. балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләрдә исәптә торучы балигъ булмаганнар арасында профилактика эше, аларны эшкә һәм ял итү чараларына җәлеп итү;

8. җәзасын үтәгән затлар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү һәм аларны яңадан җәмгыятькә яраклаштыру;

9. халыкның алкоголь һәм наркотиклар куллану дәрәҗәсен киметү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чаралары.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү максатыннан, ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын эшләгәндә 2025 ел өчен уртача статистик күрсәткечләр кулланылды, алар база күрсәткечләре буларак алынды.

Муниципаль программа бурычлары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары исемлеге һәм чараларны финанслау әлеге программаның 2 номерлы кушымтасында китерелгән.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2026-2028 еллар.

## III. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Чараларны финанслау нигездә тармаклар буенча Казан шәһәре бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акча җәлеп итү планлаштырыла.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен 1 329 267,4 мең сум каралган, шулардан: 1 283 309,8 мең сум – Казан шәһәре бюджетыннан һәм 45 957,6 мең сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

| Ел | Гомуми сумма (мең сумнарда) | Казан шәһәре бюджеты (мең сумнарда) | Татарстан Республикасы бюджеты (мең сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 2026 | 402 980,6 | 387 742,1 | 15 238,5 |
| 2027 | 441 803,1 | 426 478,7 | 15 324,4 |
| 2028 | 484 483,7 | 469 089,0 | 15 394,7 |

Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә. Аңа, Казан шәһәре бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Әлеге программа белән алдан каралмаган чыганаклардан өстәмә чаралар җәлеп

ителгән очракта, программаның заказ бирүчесе аңа тиешле үзгәрешләр кертә.

Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин.

## IV. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы

Муниципаль программаны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гамәлгә ашыруны гомуми контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты гамәлгә ашыра, аның кысаларында ел саен максатчан күрсәткечләр һәм программа чараларына чыгымнар, аны гамәлгә ашыру механизмы һәм башкаручылар составы төгәлләштерелә. Чараларны үтәү өчен җаваплы бүлекчәләрдән муниципаль программаны үтәү барышы турында мәгълүмат сорала һәм анализлана.

Чараларны финанслау тармак принцибы буенча башкарыла.

Муниципаль программаның чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына чараларның үтәлеше һәм башкаручыларга тиешле бюджетлардан бүлеп бирелә торган акчаларны үзләштерү турында, үсә бару рәвешендә һәм хисап елы өчен тулаем мәгълүмат тапшыралар.

Муниципаль программаның чараларын үтәү турында хисапның типлаштырылган формасы программаның 3 номерлы кушымтасында бирелгән.

Муниципаль программа координаторы түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

- хисап кварталыннан соң килүче айның егермесенә кадәр квартал саен, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны тормышка ашыру турында билгеләнгән форма буенча хисап тапшырырга;

- ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшырырга.

## V. Муниципаль программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм көтелә торган ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге муниципаль программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

Муниципаль программаның чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- 2025 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, 100 мең кешегә туры килгән җинаятьләр санының кимүе;

- мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләрнең ачылу өлеше әлеге төрдәге теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санында 2,0 процентка арту;

- теркәлгән җинаятьләрнең гомуми күләмендә ачылган җинаятьләр өлеше 3,9 процентка арту;

- урамнарда кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 2,1 процентка кимү;

- җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 1,9 процентка кимү;

- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 1,0 процентка кимү;

- балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләрдә исәптә торган балигъ булмаганнарның чагыштырма күләме 32,5%ка кимү;

- балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләрдә исәптә торган, ял итү чараларына җәлеп ителгән балигъ булмаганнарның чагыштырма күләме 36,4%ка арту;

- элек җинаять кылган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 4,0 процентка кимү;

- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләме 3,0 процентка кимү.

Муниципаль программа Казан шәһәрендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметүгә һәм социаль-икътисади иминлекне ныгытуга юнәлдерелгән.

Программаны гамәлгә ашыру икътисади һәм социаль өлкәләргә дә уңай йогынты ясаячак.

**Икътисади нәтиҗәлелек**

Алдап урлашу кебек (шул исәптән мәгълүмат технологияләрен кулланып) икътисади җинаятьләр, финанс тотрыклылыгы өчен җитди куркыныч тудыра. Җинаятьләрне нәтиҗәле профилактикалау – алар белән бәйле икътисади югалтуларны киметү өчен нәтиҗәле корал. Бүгенге көндә иң киң таралган һәм

җимергеч җинаять төрләренең берсе булган мәгълүмати мошенниклыкка каршы көрәшкә аерым игътибар биреләчәк.

Җинаятьчелек һәм алдап урлашу арту белән бәйле таләпләр, куркынычсызлыкны һәм тормыш сыйфатын арттыруга юнәлтелгән инновацион чишелешләр үсешен стимуллаштыра. Профилактика программасы кысаларында заманча технологияләр актив кертелә:

- җинаятьләрне булдырмый калуны һәм инцидентларга оператив җавап бирүне тәэмин итүче интеллектуаль видеокүзәтү системалары;

- мәгълүмати алдап урлашуга каршы нәтиҗәле көрәшүгә һәм гражданнарны финанс һәм шәхси югалтулардан саклауга юнәлтелгән алдынгы программа чишелешләре.

**Социаль нәтиҗәләр**

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру җәмгыятькә комплекслы уңай йогынты ясарга тиеш.

Көтелгән социаль нәтиҗәләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Җәмәгать куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү: программаның төп бурычы – гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү. Бу чараларны уңышлы гамәлгә ашыру һәр кеше өчен уңайлырак һәм куркынычсызрак яшәү мохите тудырачак.

2. Балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар белән бәйле вәзгыятьне яхшырту: программа балаларның караучысыз калуын кисәтүгә, авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә ярдәм итүгә, шулай ук яшүсмерләрнең ялын оештыруга юнәлдерелгән чараларны күздә тота. Бу балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган хокук бозулар санын киметергә һәм аларның уңышлы социальләшүенә ярдәм итәчәк.

3. Халык арасында наркотиклар һәм алкоголь куллану дәрәҗәсен киметү: наркотиклар һәм алкоголь таралуга каршы чаралар комплексы җәмәгать сәламәтлегенә уңай йогынты ясаячак һәм сәламәтлек саклау системасына йөкләнешне киметәчәк.

4. Халыкның хокукый грамоталылыгын арттыру: программа кысаларында мәгълүмати кампанияләр һәм аңлату эшләре гражданнарда җаваплы хокук аңын формалаштыруга ярдәм итәчәк. Бу, үз чиратында, белмәү аркасында кылынган хокук бозулар санының кимүенә китерергә тиеш.

5. Социаль ярдәм һәм ресоциализация системасын үстерү: программа реабилитация чараларына игътибар бирә.

___

Муниципаль программага

1 номерлы кушымта

**«2026-2028 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары, чараларын финанслау**

<table>
<tr><td colspan="6">Максатлар: Казан шәһәре территориясендә җәмәгать тәртибен һәм гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, киберҗинаятьчелекне дә кертеп, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауның нәтиҗәлелеген арттыру, хокук бозуларны һәм җинаятьләрне киметү, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлектә исәптә торучы балигъ булмаганнар санын киметү</td></tr>
<tr><td colspan="6">1 нче бурыч. Хокук бозулар һәм җинаятьләрне кисәтү буенча профилактик чараларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итү</td></tr>
<tr><td colspan="6">Индикатор күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td>Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td>2025 ел<br>(база елы)</td><td>2026 ел</td><td>2027 ел</td><td colspan="2">2028 ел</td></tr>
<tr><td>Кылынган җинаятьләр саны, 100 мең кешегә, берәмлекләрдә</td><td>1912</td><td>1900</td><td>1870</td><td colspan="2">1811</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп чараларның атамалары</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны башкару вакыты</td><td colspan="3">Елларга бүлеп финанслау, мең сумнарда</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td></tr>
<tr><td>1.1. Казан шәһәрендә хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча район комиссияләре эшчәнлеген оештыру</td><td>Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре</td><td>2026–2028 еллар (кварталга 1 тапкыр)</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

Документ создан в электронной форме. № 17311-Инф от 19.02.2026. Исполнитель: Переводчики

ЕМСЭД

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. Массакүләм мәгълүмат чараларына Муниципаль программаны гамәлгә ашыру барышы, Казан шәһәре Башкарма комитетының, Казан шәһәре Думасының, шәһәрнең эчке эшләр органнарының Казан шәһәрендә җәмәгать тәртибен ныгыту өлкәсендә башкара торган эшчәнлеге турында белешмәләр тапшыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Думасы (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар (кварталга 1 тапкыр) | - | - | - |
| 1.3. 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы «Полиция турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә дәүләт һәм муниципаль органнарга һәм гражданнарга мәгълүмат бирү максатыннан Казан шәһәре Думасына җинаятьчелек һәм хокук тәртибе торышы турында еллык хисаплар тапшыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Транспорттагы Казан линия идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар (елга 1 тапкыр) | - | - | - |
| 1.4. Җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә, яшүсмерләрне һәм яшьләрне хокукый яктан тәрбияләүгә өлеш керткән предприятиеләр һәм оешмалар, уку йортлары һәм физик затлар арасында ел саен үткәрелә торган «Закон территориясе» республика конкурсында, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясендә катнашу | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан | 2026–2028 еллар (елга 1 тапкыр) | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.5. Территориаль полиция бүлекләрен һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын капиталь ремонтлау һәм җиһазландыру эшләрен оештыру, шулай ук яңа төзелә торган микрорайоннарда тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары ачу (кирәк булганда һәм финанслау булган очракта) | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар | - | - | - |
| 1.6. Җирле үзидарә органнары вазифаи затлары эшчәнлеген тәэмин итү, шул исәптән | | 2026–2028 еллар | 387 742,1 | 426 478,7 | 469 089,0 |
| 1.6.1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре (полициянең участок вәкилләре ярдәмчеләре, социаль үсеш һәм гаилә иминлеге бүлегенең әйдәүче белгечләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең патруль-пост хезмәте, Россия Эчке эшләр | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитеты, Россия | 2026–2028 еллар | 387 365,8 | 426 102,4 | 468 712,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Казан шәһәре буенча идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең миграция мәсьәләләре бүлеге белән берлектә эшләүче муниципаль хезмәткәрләр) эшчәнлеген финанслау | Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.6.2. Җирле үзидарә органнары вазифаи затлары – тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җитәкчеләре эшчәнлеген матди-техник яктан тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар | 376,3 | 376,3 | 376,3 |
| 1.7. Казан шәһәренең халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штаблары эшчәнлеген оештыру, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр эшен координацияләү | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар (даими) | - | - | - |
| 1.8. Яңа халык дружиналары төзү һәм аларга ирекле нигездә гражданнарны җәлеп итү буенча чаралар оештыру, җәмәгать тәртибен саклау һәм хокук бозуларны профилактикалауның башка мәсьәләләре | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан | 2026–2028 еллар (даими) | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| буенча ирекле халык формированиеләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыруга ярдәм итү | шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | | | | |
| 1.9. Эчке эшләр органнарының хокук тәртибен саклау өлкәсендәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлеге чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар (даими) | - | - | - |
| 1.10. Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүдә һәм хокук бозуларны профилактикалауда актив катнашкан һәм әлеге эшчәнлеккә шәхси өлеш керткән гражданнарны һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен бүләкләү | Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2026–2028 еллар (елга 1 тапкыр) | - | - | - |
